# Тыңламас башлангыч мәктәбе тарихы

- Яңа мәктәп төзелгәнче укучылар 2 катлы мәчет бинасында укыйлар.1965 нче елда бинаның матчасы чатный.Укулар 2 яклы, фермага каршы йортта алып барыла.Яңа мәктәп төзү мәсьәләсе алга баса.1966 нче елның көзендә Идел буе авылларының берсеннән әзер бура алып кайталар.



# 1965 нче елда төзелгән һәм хәзер дә кулланылыштагы мәктәп

- Кыска гына вакыт аралыгында, мәктәпне 1966-67 нче уку елының III чирегенә төзелеш бригадиры Минһаҗев Зирһамның тырышлыгы аркасында төзеп җиткерәләр. Мәктәпнең тиз аякка басуында шулай ук бригадир Әһлиев Мокадиснең дә ярдәме зур була.Яңа мәктәп бинасы элекке амбар төзелгән җиргә урнаша. Гыйнвар аенда авыл халкын, укучыларны,укытучыларны шатландырып мәктәпне ачу тантанасы була.Мәктәпне ачу тантанасында район мәгариф мөдире,Кәзкәй сигезьеллык мәктәбе директоры Гарипов Әмирхан, партия оешмасы секретаре Сәетов Мәгъсүф һәм башка җитәкчеләр катнаша.Район мәгариф бүлеге мөдире мәктәпне котлап электрофон бүләк итә. Тыңламас мәктәбе авылның көньяк-көнбатышына урнашкан. Бина агач 207 кв.м мәйдан били. Мәктәптә 4 сыйныф бүлмәсе, коридор, бер укытучылар  һәм җиһазлар бүлмәсе булдырылган. Мәктәп 4 мичкә утын ягып җылытыла.



# Ямалова Нәҗибә Ямал кызы

- 1928 нче елның 22 апрелендә Башкортстанның Илеш районы Ябалак авылында туган. 1982 нче елга кадәр Тыңламас башлангыч мәктәбендә укыта.




# Әхмәтова Вәсилә Әхмәт кызы

- 1925 нче елда Актаныш районы Аеш авылында туган. 1979 нче елда, лаеклы ялга киткәнче, Тыңламас башлангыч мәктәбендә укыта.



# Мәүлиева Зөһедия Мәүли кызы

- 1920 нче елда Илеш районы Кыргыз авылында туган. Бөре педагогия училищесын тәмамлаган. 1969-1970 нче уку елында 3 нче классларны укыта. Тыңламас балалар бакчасына тәрбияче булып күчә.



# Камалова Бания Хөҗҗәт кызы



- 1940 нчы елның 3 апрелендә Тыңламас авылында туган. Алабуга Дәүләт педагогия институтын 1965 нче елда тәмамлап Татар Ямалысы мәктәбенә эшкә кайта. 1969 нчы елдан 1987 нче елга кадәр Тыңламас башлангыч мәктәбендә укыта.

# Харисова Нәфисә Зөфәр кызы

- 1950 нче елда Актаныш районы Актанышбаш авылында туган. 1967-68 нче уку елында Тыңламас башлангыч мәктәбендә I-IV класспарда рус теле укыта.1968 нче елның 31 нче маеннан Казан Дәүләт педагогия институтына укырга



# Галиәхмәтова Әнүдә Хаҗиәхмәт кызы

- 1951 нче елның 5нче гыйнварында Актанышта туган. 1968-69 нчы уку елында I-III классларда рус теле укыта. Актаныш районы Теләкәй мәктәбенә укытырга китә.

# Хәсәнова Люзия Фәйзелхан кызы

- 1951 нче елның 2 нче сентябрендә Актаныш районы Адай авылында туган. 1968-69 нчы уку елында IV классларда укыта. Актаныш районы Бурсык мәктәбенә укытырга күчә.

# Галимова Мөсфирә

- 1951 нче елның 7 маенда Иске Кормаш авылында туган. 1968-69 нчы уку елында IV классларны укыта. 1969 нчы елның сентябреннән декабрьга кадәр Тыңламас балалар бакчасында эшли.



# Шәйгәрданова Дилфидә Заһирҗан кызы

- 1960 нчы елда Тыңламас авылында туган. Минзәлә педагогия училищесын тәмамлап 1979-82 нче елларда Тыңламас башлангыч мәктәбендә укыта.

# Нәбиева Гөлшат Рифкатъ кызы

- 1959 нчы елда Тыңламас авылында туган. 1983 нче елны Алабуга Дәүләт педагогия институтын тәмамлап Тыңламас башлангыч мәктәбенә эшкә кайта. 1983-84 нче уку елында I-III классларны укыта.

# Мәгъдәнова Ләйсән Назыйм кызы

- 1959 нчы елның 4нче июнендә Актаныш районы Тыңламас авылында туган. 1976 нчы елда Актаныш урта мәктәбен тәмамлап Казан Дәүләт университетының биология факультетында белем ала. Түбән Тагил шәһәренең Висимск тыюлыгында, 1986-87 нче елларда Төрекмәнстанның Дәүләт тыюлыгында эшли. 1987-88 нче елларда Тыңламас башлангыч мәктәбендә укыта.

# Миңнуллина Мәгавия Сафа кызы

- 1947 нче елның 20 нче июнендә Актаныш районы Яңа Балтач авылында туган. Минзәлә педагогия училищесында укыган, Алабуга Дәүләт педагогия институтының физика-математика факультетын читтән торып тәмамлаган. Тыңламас башлангыч мәктәбендә 1988-93 нче елларда укыткан.

# Муллаярова Сөмәя Тәлгать кызы

- 1966 нчы елның 19 гыйнварында Актаныш районы Кәзкәй авылында туган. Минзәлә педагогия училищесын тәмамлап,5 ел Минзәлә районы Җәмәк авылында эшләгәч, 1990 нчы елның 15 нче августыннан Тыңламас башлангыч мәктәбенә эшкә килә.1990-91 нче уку елында 3нче классларны укыта.

# Хаҗиева Гөлназ Роберт кызы

- 1973 нче елда Аеш авылында туган. 1992-94 нче уку елларында Тыңламас башлангыч мәктәбендә укыта.

# Имамгалиева Филәрия Мулланур кызы

- 1972 нче елның 30 гыйнварендә Тыңламас авылында туган. Минзәлә педагогия училищесенда, Алабуга Дәүләт педагогия институтында белем ала. 1993 нче елдан Тыңламас башлангыч мәктәбендә укыта.1993-2006 нчы елларда мәктәп мөдире вазыйфасын башкара.




# Мортазина Рания Әбүзәр кызы

- 1974 нче елның 21 нче сентябрендә Тыңламас авылында туган. 1994-97 нче уку елларында Тыңламас башлангыч мәктәбендә укыта.

# Мөхәммәтова Луиза Мәхәсим кызы

- 1976 нчы елның 13 нче февралендә Тыңламас авылында туган.Минзәлә педагогия училищесенда, Алабуга Дәүләт педагогия институтында белем ала.1995 нче елдан Тыңламас башлангыч мәктәбендә укыта. 2006 нчы елдан мәктәп мөдире вазыйфасын башкара.



# Нуретдинова Гүзәл Әхнәф кызы

- 1975 нчы елда Актаныш авылында туган. Чаллы педагогия көллиятен тәмамлап 1997-98 нче уку елларында 1 нче классларны укыта.

# Тагирова Гөлшат Мирһади кызы

- 1974 нче елның 3 нче мартында Илеш районы Кыргыз авылында туган. Уфа педагогия училищесын 1993 нче елда тәмамлаган.2000-04, 2006-07 нче уку елларында Тыңламас башлангыч мәктәбендә укыта.



# Шәрипова Сирина Хәлил кызы

- 1979 нчы елда Актаныш районы Яңа Әлем авылында туган. 2001нче елда Чаллы Дәүләт педагогия институтын тәмамлап эшкә кайта.2001-03 нче уку елларында Тыңламас мәктәбендә укыта.



# Харисова Сирена Әбүбәкер кызы

- Актаныш районы Әгъбәс авылында туган. 2002 нче елда Минзәлә педагогия училищесын тәмамлый 2002-03 нче уку елында 1 нче классларны укыта.